ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2018 г.Мензелинск №1348

# Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 21.05.2018 елдагы "Татарстан Республикасы муниципаль архивлары тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә типовой административ регламентларны раслау турында" 08.06.2016 елдагы "Архив эше буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының боерыгына үзгәрешләр кертү турында"гы №55-од боерыгы нигезендә, ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Расларга:

1.1. Муниципаль архивта сакланган һәм дәүләт милке саналган архив фондлары буенча архив документлары күчермәләрен, архив сөземтәләрен, архив белешмәләрен бирү буенча дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә административ регламентны (Кушымта №1).

1.2. Муниципаль архивта сакланган һәм дәүләт милке саналган архив фондлары буенча архив документларын кулланучыга муниципаль архивның уку залында эшләү өчен бирү буенча административ регламентны (Кушымта №2).

1.3. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашкан урыны мәсьәләләре буенча консультация буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламентны (Кушымта №3).

2. ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең 21.07.2016 елдагы архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә административ регламентны раслау турындагы №826 карары көчен югалткан дип санарга.

3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.